# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## К А Р А Р

**№ 153** **26 ноябрь 2024 ел.**

**“Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” 2018 елның 26 апрелендәге 95 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2018 елның 26 апрелендәге 95 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының “Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” карарына (14.05.2018 № 96, 22.11.2018 №125, 30.11.2018 №128, 12.09.2020 № 186, 30.12.2021 № 45, 30.09.2022 № 73, 28.11.2022 № 78, 02.03.2023 № 97, 24.06.2024 № 1 Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә:

2.2 пунктта «13 323 сум» сүзен «13 990 сум” сүзе белән алыштырырга;

2.14 пунктта «13 323 сум» сүзен «13 990 сум” сүзе белән алыштырырга;

1.2. Әлеге карар белән расланган “Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында” нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19 173 |

2. Карарны Югары Пәнәче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгы,** **М. Х. Туктаров**
**Совет Рәисе**